| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировка мәйданчыклары системасы турында**

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше системасы нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында кодексы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен стажировка мәйданчыклары системасын (алга таба – стажировка мәйданчыклары системасы, стажировка мәйданчыклары) булдыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

60 көн эчендә стажировка мәйданчыклары системасын булдыру һәм эшләтү күздә тотылган норматив хокукый актлар эшләргә һәм кабул итәргә, шул исәптән стажировка мәйданчыклары исемлеген һәм стажировка мәйданчыкларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең стажировкаларын оештыру буенча белем бирү хезмәтләре бәясенең икътисадый нормативларын билгеләргә;

стажировка мәйданчыклары системасын булдыру һәм эшләтүгә кагылышлы норматив хокукый актларда түбәндәгеләрне күздә тотарга:

өстәмә һөнәри белем бирү стажировка мәйданчыгында тулысынча стажировка рәвешендә башкарылган квалификация күтәрү программасы кысаларында алып барыла;

стажировка мәйданчыклары системасында «җитәкчеләр» категориясе вазыйфаларын биләүләренә бер ел тулмаган һәм бу вазыйфаларга беренче тапкыр билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре,

шулай ук муниципаль хезмәтнең югары һәм баш вазыйфаларын биләүләренә бер ел тулмаган һәм әлеге вазыйфаларга беренче тапкыр билгеләнгән Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр стажировкасы тиешле җирле үзидарә органнары белән килештереп оештырыла;

әлеге Указны гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка карарларны кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына тәкъдим итәргә:

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына стажировка мәйданчыклары системасын булдыруда һәм эшләтүдә, шул исәптән стажировка мәйданчыклары исемлеген билгеләүдә җирле үзидарә органнарының катнашуы буенча тәкъдимнәрен кертергә;

муниципаль хезмәтнең югары һәм баш вазыйфаларын биләүләренә бер ел тулмаган һәм әлеге вазыйфаларга беренче тапкыр билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең стажировка мәйданчыкларында һөнәри үсешен тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең стажировка мәйданчыкларында һөнәри үсешен оештыру мәсьәләләрендә дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына ярдәм күрсәтергә.

5. Әлеге Указны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү буенча дәүләт программасын гамәлгә ашыруга каралган акча исәбеннән башкарырга.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 18 август
№ ПУ-574